*Синнән күргән игелек-изгелекләрне*
*Калды бары сагынып сөйләргә.*
*Төшләреңдә күреп юрагансың*
*Керәм, диеп, кара гүрләргә.*

*Синсез үтә, улым, түзәм, ни хәл итим,*
*Иртәләрем, айлы кичләрем.*
*Еллар үткән саен, сине сагынып*
*Саташудан мин дә үләрмен.*

*Кесә телефоның башка җавап бирми,*
*Көн дә шалтыратып карыймын.*
*Ялгыз айга, йолдызларга карап*
*Үткән төннәремне саныймын.*

*Рәсемнәреңнән күзләремне алмыйм,*
*Күпме карасам да, туймыймын.*
*Киемнәреңне элеп куйдым чөйгә,*
*Үткән саен иснәп елыймын.*

*Син кайтасы юлга төбәп карыйм*
*Яшьле күзләремне талдырып.*
*Кайтмыйсың шул, балам, мәңгелеккә киттең,*
*Йөрәгемә кисәү калдырып.*

*Күпме өрсәм дә, кисәү янып китми,*
*Яшьләрем бирми кабынып китәргә.*
*Җаным-тәнем, эчем тулы ялкын,*
*Синсез авыр миңа яшәргә.*

*47 яшеңдә барып кердең гүргә,*
*Тыныч, якты булсын каберең.*
*Догаларга күмелеп ятуыңны*
*Сизеп торасыңмы, бәгырем?*

*Кулымдагы биш бармагымның берсе,*
*Сизми калдым, төште өзелеп.*
*Кара туфрак асларында, балам,*
*Караңгы гүрең хәзер мәңгелек.*

*Тыныч йокла, балам, онытмыйбыз,*
*Җыелышып яныңа киләбез.*
*Нурияң белән Рушат улың кайта,*
*Баш очыңда догалар кылабыз.*

**Саимә МОРЗАХАНОВА.**
Гали авылы,
Похвистнево районы.

# *Тел турында*

*Иң кадерле әгъза – тел белән күз,*
*Начары да шул ук тел дагән.*
*Шуның өчен Аллаһы гакыл биргән,*
*Яхшы уйлап, шуны бел дигән.*

*Күрәсең бит, телне Хак Тәгалә*
*Бигрәк эчкә куеп саклаган,*
*Тешләр белән аны урап алып,*
*Ике ирен белән каплаган.*

*Уйламыйча сүзне сөйлә дисәң,*
*Ул сүз сиңа кайгы китерә.*
*Күп ахмаклар сүзен уйламыйча,*
*Телгә хуҗа булмый, җикерә.*

*Дулый-дулый җикереп сөйләгәнгә,*
*Йөрәк кыза, тона күзләре.*
*Менә шундый сүзне тыңламыйлар,*
*Ихтыярсыз кала үзләре.*

*Акрын гына уйлап сүз сөйләсәң,*
*Телең чыкмас тештән, иреннән.*
*Бөтен җирдә сине яратырлар,*
*Һичкем кумас туган илеңнән.*

*Тел ачыклый бик күп чынбарлыкны,*
*Нинди кеше, нинди холыклы,*
*Тел таныта синең кем икәнне,*
*Дошманлыкны һәм дә дуслыкны.*

*Үзең матур телең начар булса,*
*Аңламыйлар синең сүзеңне.*
*«Әле кичә нәрсә сөйләдең?» - дип,*
*Ачырмыйлар кайчак күзеңне.*

*Тел әйткәнне элеп алалар да*
*Бәйләнәләр сиңа барсы да,*
*Күрсәтә ул гуя көзге кебек,*
*Кем икәнең халык алдында.*

*Әгәр телгә хуҗа булалмасаң,*
*Китерә ул кайгы, хәсрәт.*
*“Телең тыйсаң - тыныч яшәрсең”, - дип*
*Әйтте миңа бер зур хәзрәт.*

*Мин дә аның әйткән туры сүзен*
*Игътибарлап, сынап карадым.*
*Кемгә телем суздым - дошман булдым,*
*Телне тыйгач аңа ярадым.*

*Яхшылык та, яманлык та*
*Бер тел белән табыла,*
*Бозылышуга да сәбәпче*
*Шул сөяксез тел була.*

*Тел адәмне гүргә кертә,*
*Тел адәмне аздыра,*
*Тел белән әйткән көфер сүз*
*Иманыңнан яздыра.*

*Туры юлга кертүгә дә*
*Сәбәп була тел генә,*
*«Ул синең чын дошманың», - дип*
*Хурламаек гел генә.*

*Тел белән Коръән укысаң,*
*Мәгънәсен уйлый күңел,*
*Син хуҗа булсаң телеңә,*
*Ул сиңа дошман түгел.*

*Моң-зарыңны аңлатасың*
*Тел белән, сүзең белән.*
*Бер Ходайга ялварасың*
*Тәүбә итеп тел белән.*

*Тел белән дога кыласың,*
*Бер Ходайга ышанып.*
*Дошманың - шайтан ләгингә*
*Йөрмәсән син алданып.*



Намаз кылучы кешенең фикерләре читкә китмәскә тиеш. Әмма үзеңне бу халәттә ничек саклап калырга соң? Иң әһәмиятлесе – намазны һәрнәрсәдән өстен һәм бөек итеп күрергә кирәк, аны көндәлек тормышыңнан алып ташларга мөмкин булган бернәрсә итеп түгел, ә хәятеңнең аерылгысыз бер өлеше, яшәү рәвеше итеп кабул итәргә кирәк. Намаз укырга кеше зиһене һәм акылы белән әзерләнсен. Ул «хәзер Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәм» дип уйларга тиеш. «Бәлки, бу намазым соңгысыдыр» дигән фикер дә кешегә намазын калдырмаска ярдәм итә. «Намазны Кәгъбә каршында укыйм», дип күз алдына китерергә кирәк. Азанны да хөрмәтләргә, аны тыңларга, намазга кереш итеп кабул итәргә тиешбез. Намаз вакытында күзләр уңга-сулга йөрергә тиеш түгел. Тышкы дөнья белән бәйләнешләрне өзәргә кирәк. Намаздагы сүрәләрне аңлап укырга тырышыгыз, мәгънәләрен белегез.

Камил кылынган намазлар гөнаһлардан арындыра. Намаз тәүбә белән үрелеп барырга тиеш, акыл белән кылынган намаз ул – тәүбәдер, әмма һәр тәүбә намаз түгел.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

# *Телнең афәтләре*

*Бел ки, сүзләр дүрт төрлегә бүленә: беренчесе - фәкать зарар китерер. Икенчесе - зарар һәм файда китергән сүзләр. Өченчесе - ни зарары, ни файдасы булмаган сүзләр. Әмма болар вакытны бушка үткәрүләре белән зарарлы. Дүртенчесе - фәкать файда китергән сүзләр. Димәк, мөэминнәр сүзләрнең дүрттән өчен ташлап, дүрттән берен генә сөйләргә тиеш.*

## Кирәкмәгән сүзләр сөйләү

Кирәк булмаган сүзләрне сөйләүче исламның гүзәллегеннән чыккан булыр. Пәйгамбәребез әйтте: *«Кирәкмәгән нәрсәләрдән баш тарту - кешенең мөселманлыгының гүзәллеге ул»*. Локман Хәким бер ел Давыд галәйһис-сәләм янында калды. Давыд нәрсәдер ясый иде. Локман аның нәрсә эшләгәнен бик тә белергә теләде, ләкин сабыр итеп сорамады. Ниһаять, Давыд әйтте: “Бу кемгәдер бик кирәкле әйбер, ләкин күп кешегә бөтенләй кирәкмидер”.

Риваять ителде: Пәйгамбәребез белән сугышта катнашкан бер егет шәһид булгач, аның ачлыктан корсагына таш бәйләп йөргәнен күрделәр. Әнисе аның йөзендәге тузанын сөртеп, җәннәткә хисапсыз керер инде, диде. Пәйгамбәребез әйтте: *«Кайдан беләсең, бәлки, ул үзенә кирәксез сүзләр сөйләгәндер».* Ягъни кирәксез сүз сөйләүчедән кыямәт көнне хисап таләп ителер икән, хәтта ул шәһид булып үлсә дә.

Беркөнне Пәйгамбәребез әйтте: *«Бу сәгатьтә бу капкадан җәннәт әһеле керәчәк».* Соңрак Абдуллаһ бин Сәлам эчкәре керде. Моның турында аңа хәбәр биреп сорадылар: «Йә Абдуллаһ, син нинди гамәл кыласың, мондый бәхеткә ирештең?» Ул әйтте: «Минем гамәлем бик аз, ләкин мин кирәксез сүзләр сөйләшмәдем вә кешеләр турында яман сүз сөйләмәдем».

## Батыл вә гөнаһ булган нәрсәләр турында сөйләшү

Боларга үз гөнаһларыңны яки башкаларның гөнаһларын башка берәүгә сөйләү, фәхеш көлдергечләр сөйләү керә. Пәйгамбәребез әйтте: *«Кайберәүләр сөйләгән сүзләренә әһәмият бирмиләр, ләкин бу сүзләр аны я җәһәннәмгә, я җәннәткә илтәләр».*

## Бәхәсләшергә ыргылып тору

Шундый кешеләр бар ки, берәү бер сүз әйтсә, шунда ук аның киресен исбатлап, ул алай түгел, ә болай, дип бәхәсләшә башлыйлар. Алар, син ахмак, син ялганчы, син җәһил, мин исә зәки, акыллы, хак, дип әйтергә телиләр. Мондый кешеләр ике төрле авыруга бирешкән: берсе - тәкәбберлек, икенчесе - җанварлык. Тәкәбберлеге аңлашыладыр, ә җанварлыгы - теле кешенең хәтерен калдыруындадыр. Пәйгамбәребез боерды: *«Сөйләшкәндә бәхәсне калдырып, батыл сүзләр сөйләмәгән кеше өчен җәннәттә бер сарай ясалыр. Әгәр хак җавапны бирмичә, сабыр итсә, бу сарай җәннәтнең иң югары җиренә куелыр».* Чөнки хакны сөйләмәскә сабыр итү ялганны сөйләмәскә сабыр итүгә караганда кыенрак, Пәйгамбәребез әйтүенчә: *«Кеше хаклы булып та, бәхәстән тыела алмаса, аның иманы тулы түгел».* Пәйгамбәребез әйтте: *«Бәхәснең кәффәраты - ике рәкәгать намаз уку».* Бәхәскә бер мисал: берәү хаталы сөйләшсә, аның хатасын табып күрсәтү. Бу - хәрәм гамәл. Чөнки бу вакытта хаталанган кешенең кальбе рәнҗи. Мөселманны рәнҗетү исә хәрәм. Локман Хәким улына әйтте: «Бәгырем, галимнәр белән бәхәсләшмә, сине дошманга санарлар». Малик бин Динар хәзрәтләре әйткән: *«Бәхәс диннән түгел. Бөтен сәләфләр бәхәстән качканнар. Фәкать дошман бидгатьче булганда, аның белән Коръән һәм хәдис кулланып бәхәсләшкәннәр. Файда бирмәгәнне күрсәләр, аның яныннан киткәннәр».*

## Мал өчен яки казый каршында низаглашу

Моның да афәте зур. Пәйгамбәребез әйтте: *«Мәгълүматы булмыйча, берәрсе белән низаглашкан кеше, низагны туктатканчы, Хак Тәгаләнең ачуында булыр»*.

## Ачуланып бозык, чирканыч сүзләр сөйләү

Пәйгамбәребез әйтте: *«Яман сүз сөйләгәннәргә җәннәт хәрәм».* Янә әйтте: *«Җәһәннәм халкы арасында шундый кешеләр булыр, аларның авызыннан чыккан сасы искә чыдый алмыйча, бөтен җәһәннәм халкы, болар кем, дип сорар. Болар кайда фәхеш*

№ 14 (1141), 31 март 2012 ел

Бердәшлек